**Ачык дәрес.- 2006.**

# *Җырларыңда бар моңнарың*

**Әдәби-музыкаль композиция**

***<u>МАКСАТ</u>: Бөек композитор Сара Садыйкованың тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру;***

***Композиторның музыкаль драма, комедияләр өчен иҗат иткән әсәрләрен киң катлау укучыларга җиткерү;***

***Укучыларда халык композиторы иҗатына ихтирам, мәхәббәт тәрбияләү.***

***Зал бәйрәмчә бизәлгән. Уртада Сара Садыйкова портреты, стеналарда композиторның тормышын, аның иҗади эшчәнлеген тасвирлаучы фотокүргәзмә. Стендка Сара Садыйкова турындагы китаплар, ул язган җыр ноталары күргәзмәсе куелган.***

**<u>1 УКУЧЫ</u>.**
Күңелдәге якты хатирә булып
Җырың калды синең мәңгегә.
Җан- йөрәкнең сафлык, чисталыгын
Саклар тора җырың бүген дә.

**<u>2 УКУЧЫ</u>.**
"Җидегән чишмә"ярларында
Балкый "Шәйморза утлары."
Хәтереңдәме "Агыйдел сылуы”ның,
"Казан кичләре"ндәге хисләре.
Тормышка моң булып килдең дә,
Онытылмас җыр булып балкыдың.
Сәйдәшләрдән алган фатихаң белән
Милләтнең нурлы йөзен саклadың.

**<u>3 УКУЧЫ</u>.** Халкыбызның моң чишмәсе, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисткасы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, мәшһүр композитор, җырчы Сара Садыйкованың тууына 100 ел. Кол Галиләр, Тукай, Җәлилләр, Сәйдәш, Җиһановлар белән бергә янәшә басып торучы Сара апа Садыйкова.

**<u>Алып баручы</u>**. Татар опера театрына нигез салучыларның берсе һәм аның моңлы тавышлы солисткасы, композитор буларак 400 дән артык җыр иҗат иткән, татар музыкасына беренчеләрдән бу-
лып танго стилен кертүче, вальс иҗат итүче Сара ханым Гариф кызының бүген юбилей кичәсе. Халкыбызның сөекле композиторына багышланган әдәби-музыкаль кичәбезне башлыйбыз.

**Җыр башкарыла. "Үз илемдә" Г.Зәйнашева сүзләре.**

**<u>1 УКУЧЫ</u>.** 1906нчы елның 1нче ноябре. Аның дөньяга килгән ноктасы - Казанның хәзерге Париж коммунасы урамындагы иске генә ике катлы 18 нче йорт. Булачак әти белән әни - яшь Бибигайшә белән яшь Гариф парлашып

шушы йортка кунакка килгән булалар. Һәм Сара, туган тиешле апалары фати-рында, җырлап - биеп күңел ачып утырган мәҗлес вакытында, дөньяга килә. Гармунлы, җырлы, биюле балачагын искә төшергәндә, Сара апа әтисе белән әнисе турында бик зур мәхәббәт белән сөйли, "әткәй, әнкәй" дип өзелеп әйтүеннән үк, аның әти-әнисенә хөрмәте сизелеп тора. Чынлап та, яратырлык итеп, матур итеп тәрбия биргәннәр алар Сара апага. Балаларын белемле итәргә тырышканнар, аларның җырга-биюгә булган сәләтләрен сүндермәгәннәр, киресенчә, музыканы, бию сәнгатен аңларга өйрәткәннәр, Сараның укыр вакыты җиткәч, әти-әнисе чорында алдынгы карашлы булган Фатиха Аитова оештырган "татар кызлар гимназиясе"нә белем алырга илтәләр. Менә шул елларда ук инде Сараның белемгә ихтыяҗы арта, халкыбызның борынгы көйләренә мәхәббәте үсә. Еш кына Сара сеңлесе Разия, энесе Хафиз, Салих белән шаярып, үзенең "артистлыгын күрсәтә". Педагогия техникумында уку Сараның иңнәренә яңа канатлар үстереп җибәрә. Уку чорында ул татарның беренче композиторы Солтан Габәши белән очраша, уку йорты әзерләгән спектакльләрдә җырлы рольләрдә уйный, Казанда үткәрелгән концертларда катнаша.

**<u>2 УКУЧЫ</u>.** 1922 нче елда Татарстан автономияле республикасы каршындагы Мәгариф Комиссариаты аны Мәскәүнең Чайковский исемендәге консерваториясенә укырга җибәрә. Сара имтихан
нарны үтә һәм консерваториянең махсус бүлегенә кабул ителә. Менә ул Чайковский исемендәге консерватория укучысы! Сара консерватория бина-сыннан атылып чыга. Менә ул паркларда, бакчаларда алтын көз тантана иткән балкышка елмаеп атлый. Атламый, оча, шатлыктан, бәхеттән канатланган ул. Битләренә тиеп-тиеп киткән сары яфраклар яуган бу алтын көз аның колагына бик моңлы көй көйли кебек. Сарага бөтен Мәскәү, бөтен дөнья тоташ бер көй, мең тавышлы җыр җырлый
кебек тоела. Илебез кичергән авыр елларның хатирәсе яшь Сараның күңелендә туган моңлы образлар булып сәхнәгә менә.

Сараның күңелендә бөреләнеп кенә килгән беренче мәхәббәт хисләре дә консерваториядә укыган елларында кабынып китә. Газиз Вәлитов - сәхнә псевдонимы Айдарский - хәзерге Яшел Үзән районының Айдар авылында туып үскән.

1925 нче елда, Татарстан республикасы төзелүгә 5 ел уңае белән, С.Габәши, Г. Әлмөхәммәтов һәм В.Виноградовлар "Сания" операсын иҗат итәләр. Татар театры сәнгате тарихында беренче тапкыр опера спектакле куела.

Шул ук елны Сара белән Газизнең кызлары туа. Кап-кара күзле, бөдрә чәчле бу кызга Әлфия дип кушалар.

**Җыр "Беренче мәхәббәт" Ә. Рәшитов сүзләре.**

1933 нче елның 4 нче апрелендә ВКП (б) ның Татарстан өлкә комитеты Татарстанда аерым музыкаль театр - Опера театры оештыру турында карар чыгара, ә инде 1934 нче елның январеннан укулар башлана, шул уңайдан Наркомпрос 25 кешедән торган бригаданы Мәскәүгә яңадан укырга җибәрә, алар арасында Сара Садыйкова да була. Шул ук елларны тормыш иптәше

Газиз дә җитди авырый башлый. Каты авырулардан соң тормыш иптәше 1933 нче елның 1 нче ноябрендә вафат була.

**Җыр "Бөтен гомергә".**

**<u>3 УКУЧЫ</u>.** 1938 нче ел, укулар тәмам. Студия белән саубуллашып, бер төркем артистлар һәм композиторлар Казанга кайталар.

Казан!...

И Казан! Нурлы Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан!...Тукай Казаны...

Мәскәүдән кайткан улларын, кызларын нуры белән балкып, дәрте белән ашкынып, моңы белән назлап каршы ала!.

1939 нчы елның 17 нче июне. Качалов исемендәге Казан Дәүләт Зур Драма театры бинасы. "Качкын" спектакле белән Татар Опера театры ачыла. Беренче тапкыр пәрдә ачылып, зур сәнгать юлы башлана. Бер-бер артлы татар опералары, музыкаль комедияләре иҗат ителеп, сәхнәгә куела. "Галиябану" (М.Мозаффаров), "Ирек", "Илдар" (Н.Җиһанов), "Башмагым" (Җ.Фәйзи) спектакльләрендә Сара Садыйкова җаваплы рольләрдә уйный, кызыклы образлар иҗат итә

**<u>1 УКУЧЫ</u>.** 1941 нче елның 22 нче июненә ил өстенә Гитлер фашистлары ябырылып килә. Көнбатышта туплар ярыла, шәһәрләр җимерелә, авыллар яндырыла, кан коела. Сара гына түгел, гомумән җыр, музыка тынып кала. Ничек яшәргә. Фронттан да көн саен күңелсез хәбәрләр килеп тора, бертуган энесе Салих та сугышка китә. Сөйгәне Юлий Крещелюнасны югалту ачысыннан туган "Көтәм сине" - җыры Сара ханымның зур әһәмияткә ия булган беренче көе, беренче иҗат җимеше. Шулай уйламаганда туган шушы көй аны олы юлга - музыка иҗат итү юлына алып керә. Көтмәгәндә микәнә..Күңел түрендә ул күптән, күптән бөреләнгәндер, чөнки ул кинәт кенә аткан чәчәк кебек дөньяга килә. Сара госпитальләрдә бик еш булып, яралы солдатлар каршында җырлап, бик күп шефлык концертларында катнаша.

**<u>2 УКУЧЫ</u>.** Сара Садыйкова композиторлык иҗатына беренче адымнарын ясаганда, Салих Сәйдәшевның йогынтысы турында да берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр. Шунысы игътибарга лаек, Сара Садыйкова иң беренче көен нәкъ менә Салих Сәйдәшев кушуы буенча яза.Театрның 1931-32 нче елгы сезоны. Кәрим Тинчуринның "Кандыр буе" музыкаль драмасына Фәридә ариясен иҗат итә. Аннан соң Кәшифә Тумашева яңадан сәхнәләштергән М.Фәйзинең "Ак калфак" спектакльленә көйләр иҗат итә. Шулай итеп, Сара Садыйкова спектакльләргә
музыкалар язып, композиторлык эшенә тирәнрәк керә бара, аның музыкалары спектальләрдә генә түгел, зур эстрада сәхнәләренә
дә үтеп керә. Татар һәм башкорт опера, академия театрларында гөрләп барган 'Туй узгач", "Кияүләр", "Кара йөзләр", "Бер картлыкта, бер яшьлектә", "Энҗеле калфак" һ. б. - шуларның
бер мисалы. Канатланып җырлар язуы Сара Садыйкованың үзе җырларга теләп ашкынган күңеленә җан рәхәтлеге бирә. Үзенең сәхнәдә җырламавына ул инде борчылмый, әйтерсең шулай кирәк булган, аның җырчылыгы, чишмәнең чыганагы шикелле, композиторлык иҗатының башлангычы булып

яшьлегендә кала. Сандугачтай сайрап сәхнәләрдә кичергән бәхетле минутлары, үткән гомерен яктыртып, матур хатирәләр булып калалар.

**<u>3 УКУЧЫ</u>**. 1960 нчы еллардан башлап, Сара Садыйкованың композиторлык иҗагы яңа баскычка күтәрелде. Аның күп кырлы композиторлык иҗатында киң мөмкинлекләр ачылды. Җырларын Габдулла Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе артистлары бик теләп үзләренең репертуарларына кертә башладылар. Аның җырларын башлап җырлаучыларның кайсы
берләре: Мәрьям Рахманкулова, Фәхри Насретдинов, Җәвәһирә Сәләхова, Рәисә Билалова, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Вафирә Гыйззәтуллина, Хәйдәр Бигичев, Нәфисә Василова. Һәркайда аның җырлары яңгырый, һәркайда аның әсәрләрен тыңлыйлар. Татарстан радиосы аңа эфирның киң колачын ачты, аның җырлары бер-бер артлы магнитофон тасмаларына язылды, аның җырларыннан гына торган зур концертлар тапшырыла башлады.

Һәр җырның үз моңы, һәр җырның үз тарихы. Җыр ул - шагыйрь белән композиторның иҗат җимеше, аларның тыңгы-сыз эзләнүләренең татлы җимеше. Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда -җыр мәңге үлми! Җыр ул яшәү коралы. Сибгат Хәким сүзләре белән әйтсәк "Иң бәхетле җыр - шагыйрьдән халык арасына күчкән җыр". Хәер, Сара Садыйкова үзе дә еш кына: "Мин җырларымны җырлаган, тыңлаган кешеләрнең күңеле яхшырсын өчен язам", - дип кабатларга ярата. "И язмыш,язмыш" җыры - Сибгат Хәким белән Сара Садыйкованың бергә иҗат иткән иң яхшы җырларының берсе. Бу җыр, бик күп җырчыларның репертуарыннан төшмичә, бик күп еллар яңгырап халык күңелендә яши. Аерата бер моң белән сугарылган "Сусау" җыры туган якка тирән мәхәббәт хисләре белән үрелгән.

**"Сусау" җыры язмада тыңлана.**

**<u>1 УКУЧЫ.</u>** "Җидегән чишмә" җыры Сара Садыйкованың елдан - ел үсеп барган иҗатын иң югары баскычка күтәргән
әсәрләренең берсе. Бу җырның музыкасы борынгы көйләребезнең иң матур сыйфатларын үзенә туплаган, шул ук вакытта за
манча интонацияләр белән бизәлгән. Бу җыр күңелгә тиз керүчән, йөрәккә ятышлы, ягымлы мелодиягә нигезләнгән, шунлыктан
ул чын мәгънәсендә халыкчан. Композитор Җәүдәт Фәйзи халыкчанлык турысында менә нәрсә дигән иде: "Композиторның алдында торган иң изге бурыч - халыкчанлык принцибын саклау һәм халыкка аңлаешлы әсәр язу. Халыкчанлык ул - фольклордан формаль файдалану гына түгел, ә бәлки үз халкыңның көйләрен, аның аһәңен күңеленә сеңдереп, табигый рәвештә музыкаль фикер йөртү методы". "Җидегән чишмә"не җидегән йолдыз гына күреп калмады, меңләгән йолдызлар, меңләгән күңелләр күреп отып алды һәм йөрәк түренә салды бу җырны. "Җидегән чишмә" җыры ил язмышын, халык язмышын чагылдырган "Карурман", "Уел", кебек җырлар биеклегенә күтәрелгән үлмәс җыр ул. Зөһрә Сәхәбиева бу җырны шулкадәр ягымлы, шулкадәр җан җылысы белән башкара, ихтыярсыздан сине әллә нинди матур хыяллар дөньясына алып китә: туган як болыннарына, челтерәп аккан чишмә

буена, яшьлеккә, беренче сөйгән ярларын янына чакыра.

**"Җидегән чишмә" язмада тыңлана.**

**2 УКУЧЫ**. Сара Садыйкованың музыкаль иҗаты халыкчанлык белән сугарылган. Аның иҗат чишмәләренең чыганаклары - халык көе, халык моңы. Халык көен, халык моңын Сара Садыйкова заманча аһәңнәр белән баетып, заманча ритмнар
белән үрелдереп, яңа моңнар тапты. Гомумән аның иҗатына бай тематика, җырларына төрле характерлылык хас. Киң сулышлы гәүһәр җырлар, маршлар, салмак агышлы лирик җырлар, мәхәббәт-дуслык җырлары, күңелле вальслар, бию көйләре
һ.б. шундый әсәрләр язды.

**3 УКУЧЫ**. Кызы Әлфия Айдарская - 22 ел буена татар дәүләт опера һәм балет театрында балерина, 1988 нче елны дөнья күргән "Балет любовь моя" китабы авторы, кияве Всеволод Иванович Грекулов - Татарстанның атказанган артисты, татар дәүләт симфоник оркестрының велончисты, Сара ханымның оныгы Слава Грекулов шулай ук музыкант, хатыны балерина Надежда Ша-ронова. Сара Садыйкованың бертуган сеңлесе җырчы Разия Садыйкова шулай ук Мәскәүдә укып кайтып, Казанда татар операсы солисткасы булып эшли, аннары озак еллар 1категорияле хор солисткасы була.

"Сания"дә - Сания, "Эшче" операсында - Сәлимә, "Башмагым" музыкаль комедиясендә - Сәрвәр, "Наемщик" музыкаль драмасында - Зөбәрҗәт... Татар опера театры сәхнәсендә матур образлар тудыра алганы һәм Милли опера сәнгатебезне үстерүгә күп көч куйганы өчен, Сара Садыйковага шул елларда ук, “Татарстанннның атказанган артисткасы" дигән мактаулы исем бирелә.

**1 УКУЧЫ**. Сара апаның үзенә генә хас үзенчәлеге бар иде - ул да булса калфак. Энҗеле калфагын киеп, йөзек кашы кебек балкып сәхнәгә чыга иде. Шул калфаклары белән дә кадерле ул безгә Сара Садыйкова. Ул калфаклар да Сара апаның үзе кебек әллә нинди моң. әллә нинди матур көйләр беләләр шикелле. Чынлап та ул калфакларның үзенә күрә сере дә бар икән. "Калфак кигән хатын-кыз матур, күркәм күренә, калфак кигәч үзеңне әдәпле тотасың, чөнки башына калфак кигән хатын - кыз әдәпсез була алмый" дия торган иде композитор ханым.

**2 УКУЧЫ**.Сара Садыйкованың республикабыздагы күп кенә авылларга багышланган җырлары: "Актаныш таңнары", "Арча кичләре", "Чынлы авылы", "Балкый Шәйморза утлары", "Минзәләм ягы", "Балтачым"- авыл кешеләре белән якыннан аралашу нәтиҗәсе. Бу җырларда туган җиргә мәхәббәт, анда
яшәүче кешеләргә соклану шулкадәр көчле, композиторның мәхәббәте тыңлаучыга күчә.

**Җыр "Казан кичләре" Х.Туфан сүзләре**

Сара Садыйкова үзенең әби-бабалары, әнисе яшәгән Апас районы Тутай, Кызыл Тау авылларына, туган ягым дип, бик еш кайтып йөри. Чөнки аның моң чишмәләре, зур дәрья кебек киң иҗатка юл башы шушы авыллардан башлана. Биредә туып - үскән, соңрак Казан пристанендә эшләгән Әхмәдиша кызы Бибигайшә ханым, әнисе Нәгыймә ападан ятлаган шигырь-мөнәҗәтләрне халык көйләрен кечкенә Сара күңелендә дә сала. Аның күп кенә җырлары шушында туа. "Иртәңге нур", "Дөнья матур, дөнья киң" дигән матур көйләре Тутай кырларында тургай сайравын тыңлап иҗат ителгән.

**3 УКУЧЫ**. Бәхетле язмыш! Сүрелмәс яшьлек! Опера җырчыларының сәхнә гомере бик кыска ул. Олыгаеп барган Гомер юлында аның икенче таланты ачылу, аны
тагын да югары дәрәҗәгә күтәрде. Үзе исән чагында, үзе үк исемен мәңгеләштерде.
Тормыш дәвам итә. Аның җырлары яши. Идел, Казансу нинди тирән уелып, тирән моңнар көйләп ага. Чишмәләр ничек матур челтерәп, кояш нурында җем-җем килеп, көмеш кебек җыр сузалар!, ә кошлар, кошлар, кояшка, айга, йолдызларга җитсен моңыбыз дигәндәй ничек матур итеп сайрыйлар, ә кешеләр, кешеләр җырлый.. . Һәр тарафта җыр яңгырый! Тормыш җыр белән киләчәккә бара!... Бу җырларда Сара Садыйкова моңнары да бар!...-Сара Садыйкова үзе җыр, үзе моң ул.

**1 УКУЧЫ.**
Җырларыңда синең бар моңнарың
Җырларыңда синең бар сагышың.
Онытылмас моңнар бүләк иттең,
Без җырларбыз синең хакыңда.

Җыр башкарыла. “Белегез шуны" И. Фазлуллин сүзләре.

**ГАЙНЕТДИНОВ М.С.**
Сарман районы Шәрләрәмә урта гомуми белем бирү мәктәб